**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**15.10.2014** г.Казань **№ 01-02/639**

Татарстан Республикасы Юстиция
министрлыгы Регламентын раслау
турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (алга таба – Министрлык) структур бүлекчәләренең аларга йөкләнгән бурычларны хәл итү буенча эшчәнлекләрен оештыру һәм аның тәртибен камилләштерү максатыннан, боерам:

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының әлеге Регламентын (алга таба – Регламент) расларга.
2. Беренче урынбасарга, министр урынбасарларына, эшләр белән идарә итүчегә, министр ярдәмчесенә, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, Министрлык хезмәткәрләренә гамәли эшчәнлектә Регламент нигезләмәләренә таянырга.
3. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2006 елның 7 июлендәге 01-01/42 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип санарга.
4. Әлеге боерыкны үтәүне контрольдә тотуны эшләр белән идарә итүче Н.И.Латыповка йөкләргә.

Министр вазыйфаларын башкаручы Р.И.Заһидуллин

Татарстан Републикасы юстиция
министры вазыйфаларын
башкаручының 2014 елның
боерыгы белән расланган

# Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы Конституциясе, “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында” 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының (алга таба – Министрлык) билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә анык вазыйфаларын гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген оештыруның төп кагыйдәләрен билгели.

1.2. Регламент Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 5 гыйнварындагы 563 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты регламенты), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 22 февралендәге 68 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмә (алга таба – Министрлык турындагы нигезләмә) нигезендә эшләнгән.

1.3. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының закон проектларын эшләү һәм норма чыгару эшчәнлеген хокукый тәүмин итү һәм координацияләүне, шәхеснең һәм дәүләтнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүдә ярдәм итүне, республика коррупциягә каршы программасын үтәүне контрольдә тотуны, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары бердәм банкын формалаштыру һәм алып баруны, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып баруны, хокукый мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыруны, Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру, матди-техник һәм финанс ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыручы органы булып тора.

1.4. Министрлык Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тэмин итү һәм авыр тормыш шартларында калган гражданнарга экстрен хәлләрдә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында карар кабул итү өлкәсендә вәкаләтле органы булып тора.

1.5. Министрлык үзенә йөкләнгән бурычларны һәм вазыйфаларны гамәлгә ашырганда башкарма хакимиятнең федераль органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, суд

берләшмәләре органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

1.6. Министрлык белән вазыйфасына Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләп куела һәм азат ителә торган министр җитәкчелек итә.

1.7. Министрның беренче урынбасары һәм министр урынбасарлары, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча совет тәкъдиме буенча, вазыйфаларына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләп куелалар һәм азат ителәләр.

1.8. Министрлыкның структур бүлекчәләре функцияләре һәм вәкаләтләре әлеге структур бүлекчәләр турындагы Татарстан Республикасы юстиция министры (алга таба – министр) тарафыннан раслана торган нигезләмәләр белән билгеләнәләр.

1.9. Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хокуклары һәм бурычлары вазыйфаи регламентлар белән, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына кермәгән вазыйфаларда булучыларныкы – министр тарафыннан расланган вазыйфаи инструкцияләр белән билгеләнә.

## II. Министрлык җитәкчелеге, структур бүлекчәләр җитәкчеләре вәкаләтләре

2.1. Министр “Татарстан Республикасында дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында” 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә:

Министрлык эшчәнлеген оештыра;

башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләтнеке булган һәм дәүләтнеке булмаган оешмаларга мөнәсәбәттә Министрлыкны тәкъдим итә;

үзенең урынбасарлары арасында вазыйфаларны бүлә, шулай ук Министрлыкның структур бүлекчәләре җитәкчеләренең вазыйфаларын билгели;

Министрлык тарафыннан аның компетенцияләренә керә торган функцияләр һәм вәкаләтләрнең үтәлеше һәм Министрлык тарафыннан кабул ителә торган хокукый актларның законлылыгы өчен, оештыру-бүлү эшчәнлегенең гамәлгә ашырылуы өчен шәхси җаваплылык тоя;

Министрлык, аның структур бүлекчәләре эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар чыгара;

Министрлык структурасына керүче структур бүлекчәләр турындагы нигезләмәләрне раслый;

Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләрен, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булып тормаган вазыйфалардагы хезмәткәрләрне вазыйфаларга билгели һәм азат итә;

Министрлык турындагы нигезләмә, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән башка вазыйфаларны гамәлгә ашыра.

2.2. Министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче Министрлыкны аның эшчәнлеге өлкәсендәге аерым мәсьәләләр буенча тәкъдим итәләр, әлеге Регламент нигезендә структур бүлекчәләр эшчәнлеген

координацияләүне һәм күзәтчелек итүне дә кертеп, Министрлык функцияләрен гамәлгә ашыруны оештыралар һәм координациялиләр.

2.3. Министрның беренче урынбасары хокукый экспертиза һәм норма чыгару эшчәнлеге, норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү, мәгълүмат-аналитика эше, координацияләү һәм планлаштыру бүлекләре, шулай ук түләүсез юридик ярдәм күрсәтү секторы эшчәнлеге белән идарәне гамәлгә ашыра.

Министрның беренче урынбасары министрның авыруы, отпускага китүе, командировкага китүе белән бәйле рәвештә вакытлыча урынында булмавы чорында министр боерыгы белән аның вазыйфаларын башкаручы итеп билгеләнә.

Министрның беренче урынбасары гражданнардан һәм оешмалардан хокукый мәсьәләләр, шулай ук Министрлыкның билгеләнгән эшчәнлек өлкәсенә кагылышлы мәсьәләләр буенча кергән мөрәҗәгатьләргә Министрлык исеменнән җавапларны имзалый, җирле үзидарә органнарына хокукый ярдәм күрсәтү һәм Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеген тәэмин итүгә кагылышлы мәсьәләләрдән тыш.

2.4. Министр урынбасары җирле үзидарә өлкәсендә норматив хокукый эш һәм муниципаль регистрны алып бару бүлеге, җирле үздарә органнарына хокукый консультация-методик ярдәм бүлеге, территориаль оештырылыш һәм җирле үзидарә өлкәсендә күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү секторы эшчәнлеге белән идарәне гамәлә ашыра.

Министр урынбасары гражданнарның һәм оешмаларның җирле үзидарә органнарына хокукый ярдәм күрсәтү белән бәйле мөрәҗәгатьләренә Министрлык исеменнән җавапларны имзалый.

2.5. Министр урынбасары җәмәгать судьялары эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге, җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру-хокукый тәэмин итү бүлеге, хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге эшчәнлеген, шлай ук Министрлыкта контракт нигезендә эшчәнлек белән җитәкчелекне гамәлгә ашыра.

Министр урынбасары гражданнарның һәм оешмаларның җәмәгать судьялары эшчәнлеген тэмин итү белән бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатьләренә һәм Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары хезмәткәрләре мөрәҗәгатьләренә җавапларны имзалый.

Министр урынбасарының вакытлыча урынында булмавы чорында аның аерым вәкаләтләрен үтәү министр боерыгы белән министрның башка урынбасарына яки структур бүлекчә җитәкчесенә йөкләнергә мөмкин.

2.6. Эшләр белән идарә итүче оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге белән җитәкчелекне гамәлгә ашыра. Эшләр белән идарә итүче үз вазыйфасына министр тарафыннан билгеләнә һәм азат ителә.

2.7. Вазыйфалар бүленеше нигезендә министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче (аларга мондый вәкаләтләр бирелгән очракта) Министрлык эшчәнлеге оештырылышының аерым мәсьәләләре буенча оештыру-бүлү характерындагы актлар чыгара алалар, шулай ук, министрның законнар нигезендә рәсмиләштерелгән боерыклары нигезендә, Министрлык исеменнән килешүләрне имзалый алалар.

2.8. Вазыйфалар бүленеше нигезендә министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче:

дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, гражданнар һәм оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты белән хезмәттәшлек итәләр (шул исәптән хат язышалар);

тиешле структур бүлекчәләрнең эшен координацияилиләр һәм контрольдә тоталар, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә йөкләмәләр бирәләр;

дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар вәкилләре белән киңәшмәләр узыралар;

Министрлыкка кергән мөрәҗәгатьләрне, документларны һәм материалларны карыйлар;

Тиешле структур бүлекчәләр тарафыннан әзерләнгән, имзалау өчен министрга җибәрелергә тиешле документлар проектларын карыйлар һәм килештерәләр;

гражданнар һәм Министрлык хезмәткәрләрен шәхси мәсьәләләр буенча кабул итәләр;

Татарстан Республикасы законнары, әлеге Регламент, вазыйфаи регламентлар һәм министр боерыклары белән каралган башка вазыйфаларны гамәлгә ашыралар.

2.9. Министр ярдәмчесе вазыйфага аның үз вазыйфаларын үтәү чорына министр тарафыннан билгеләнә. Министр ярдәмчесенең бурычлары, вәкаләтләре өлкәсе министр тарафыннан расланган вазыйфаи регламент белән билгеләнә.

Министр ярдәмчесе министр кушуы буенча киңәшмә һәм координацияләү органнары эшендә, Министрлыкта, башкарма хакимият органнарында һәм дәүләт хакимиятенең башка органнарында һәм оешмаларда уздырыла торган киңәшмәләрдә катнаша ала.

2.10. Структур бүлекчәләр җитәкчеләре әлеге Регламент, структур бүлекчәләр турындагы нигезләмәләр, вазыйфаи регламентлар, министр боерыклары нигезендә:

структур бүлекчә белән бердәнбер җитәкче сыйфатында җитәкчелек итәләр, структур бүлекчәгә йөкләнгән функцияләр һәм вәкаләтләрнең үтәлеше, башкару дисциплинасы торышы һәм куелган индикаторлар үтәлеше өчен җаваплылык тоялар;

Министрлыкның башка структур бүлекчәләре белән хезмәттәшлек итәләр;

Министрлыкның актлар проектларын һәм башка документларын тиешле тәртиптә әзерләүне тәэмин итәләр;

гражданнардан һәм оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләрне, актлар проектларын һәм башка документларны карауны, шулай ук алар буенча бәяләмәләр әзерләүне тәэмин итәләр;

структур бүлекчәләр хезмәткәрләре арасында вазыйфаларны бүләләр, министрның беренче урынбасарына, министр урынбасарларына, эшләр белән идарә итүчегә килештерү өчен бүлек турындагы нигезләмәне, вазыйфаи регламентларны һәм структур бүлекчәләр хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләрен кертәләр;

структур бүлекчәләр хезмәткәрләренең дәүләт граждан хезмәтен узулары белән бәйле чараларны уздыруны тәэмин итәләр, шул исәптән вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү, вакытлыча эш урынында булмаганда үз вазыйфаларын

вакытлыча үтәү, квалификация күтәрү, структур бүлекчә хезмәткәрләрен бүләкләү һәм аларга җәза бирү турындагы тәкъдимнәрне кертәләр;

әлеге Регламент, структур бүлекчә турындагы нигезләмә һәм министр, министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче боерыклары нигезендәге башка вазыйфаларны гамәлгә ашыралар.

## III. Эшләрне планлаштыру һәм оештыру тәртибе

3.1. Министрлык эшен эшчәнлекнең төп юнәлешләре буенча планлаштыру Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык юлламасы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару эшчәнлеге планы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эше планы, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.2. Министрлык эшчәнлеге Министрлык эшчәнлегенең мәгълүмат-аналитика эше, координацияләү һәм планлаштыру бүлеге тарафыннан структур бүлекчәләрнең тиешле периодларга эш планнары нигезендә төзелгән еллык һәм квартал планнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.3. Киләсе кварталга Министрлыкның эш планына кертелүгә тәкъдимнәр структур бүлекчәләр тарафыннан квартал башланачак ай алдыннан килә торган айның 25 нче көненнән дә соңга калмыйча, еллык эш планына кертелүгә тәкъдимнәр – агымдагы елның 5 гыйнварыннан да соңга калмыйча бирелә.

3.4. Министрлыкның эш планнары проектлары министрга раслау өчен мәгълүмат-аналитика эше, координацияләү һәм планлаштыру бүлеге тарафыннан структур бүлекчәләр җитәкчеләре, министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары һәм эшләр белән идарә итүче белән килештерелгәннән соң бирелә.

3.5. Структур бүлекчәләр мәгълүмат-аналитика эше, координацияләү һәм планлаштыру бүлегенә узган квартал өчен эш планнарын үтәүләре турында хисапны хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы көненнән дә соңга калмыйча бирәләр.

3.6. Министрлыкның узган елдагы эшчәнлеге турындагы хисап Министрлыкның йомгаклау коллегиясе утырышына Министрлыкның структур бүлекчәләре тарафыннан бирелгән мәгълүмат нигезендә мәгълүмат-аналитика эше, координацияләү һәм планлаштру бүлеге тарафыннан формалаштырыла.

### Министрлыкның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларын планлаштыруда катнашуы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларына әзерлек тәртибе

3.7. Мәсьәләләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышында карау өчен федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, указлар, боерыклар, йөкләмәләр, Татарстан Республикасы Президентының республиканың эчке һәм тышкы нигезләре турында еллык юлламасы, Министрлар Кабинетының программалары һәм планнары нигезендә эшләнгән, министрның

беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче тарафыннан килештерелгән тәкъдимнәр структур бүлекчәләр җитәкчеләре тарафыннан, мондый тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертүгә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты регламенты белән билгеләнгән срокларны исәпкә алып, министрга кертеләләр.

Мондый тәкъдимнәр үз эченә алырга тиеш:

мәсәләнең исемен һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышында карау кирәклегенә кыскача нигезләүне;

мәсьәләнең гомуми характеристикасын һәм төп нигезләмәләрен;

тәкъдим ителә торган карарның формасын;

үтәргә ярдәм итүчеләр исемлеген;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышында карау датасын.

3.8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышлары планына кертелгән мәсьәләләр буенча материаллар, тиешле озату хаты белән берлектә, материаллар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелүгә 3 көннән дә соңга калмыйча министр каравына кертеләләр.

3.9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышының көн тәртибе проекты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты регламенты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан таратыла торган тиешле матриаллар булган элемтә чаралары аша (шул исәптән электрон документлар әйләнеше системасы аша да) кичекмәстән тиешле структур бүлекчәләр җитәкчеләренә җиткерелә.

3.10. Министрлыкка Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышына кадәр 5 көннән азрак вакыт кала кергән материаллар структур бүлекчәләр җитәкчеләре тарафыннан беренчел тәртиптә каралалар. Алар тарафыннан карала торган материаллар буенча кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кичектерүсез рәвештә министрга кертеләләр.

3.11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эш планына кертелгән мәсьәләләр буенча тиешле материаллар әзерләү йөкләнгән министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче, структур бүлекчәләр җитәкчеләре аларның сыйфаты, килештерелүләре һәм министрга үз вакытында кертелүләре өчен җавап бирәләр.

### Министрлык җитәкчеләре эшчәнлеген планлаштыру, Министрлык җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең командировкаларга чыгулары һәм аларга отпусклар бирү тәртибе

3.12. Министр үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан, Татарстан Республикасы Премьер-министры тарафыннан уздырыла торган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утрышларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан оештырыла торган координацияләү һәм киңәшмә органнары утырышларында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында, шулай ук министр өчен мәҗбүри булган башка планлы чараларда катнашу мөһимлеген исәпкә алып планлаштыра.

3.13. Министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче, структур бүлекчәләр җитәкчеләре үз эшчәнлекләрен министр тарафыннан уздырыла торган, шулай ук аның боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан, башкарма хакимиятнең республика органнары җитәкчеләре тарафыннан уздырыла торган чараларда һәм башка чараларда катнашу мөһимлеген исәпкә алып планлаштыралар.

3.14. Министрның командировкаларга китүе һәм отпускка чыгуы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесен язма рәвештә кисәтеп, Татарстан Республикасы Премьер-министры белән килештерелеп гамәлгә ашырыла.

3.15. Министрның командировкаларга китүе, отпускка чыгуы һәм авыру сәбәпле эш урынында булмавы турындагы мәгълүмат министр ярдәмчесе тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына җиткерелә.

3.16. Министрның беренче урынбасарының, министр урынбасарларының, эшләр белән идарә итүченең, структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һәм Министрлык хезмәткәрләренең командировкаларга чыгулары министр боерыгы нигезенә гамәлгә ашырыла.

3.17. Министрның беренче урынбасарына, министр урынбасарларына һәм эшләр белән идарә итүчегә отпуск бирү отпусклар графигы нигезендә һәм министрның вазыйфаларны башка зат башкаруының срогы билгеләнгән, кирәк булган очракта, вәкаләтләр чикләнү вакыты күрсәтелгән тиешле боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.18. Структур бүлекчәләр җитәкчеләренә опусклар отпусклар графигы нигезендә һәм министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче белән килештерелгән һәм вазыйфаларны алар арасында бүлгән боерыгы нигезендә бирелә.

3.19. Вакытлыча эш урынында булмаган структур бүлекчә җитәкчесе вазыйфалары аның урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла яки министр боерыгы белән әлеге структур бүлекчәнең бер хезмәткәренә йөкләнә.

3.20. Министрлык хезмәткәрләренә отпусклар отпусклар графигы нигезендә структур бүлекчә җитәкчесе, министрның беренче уынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче белән килештерелгән һәм вазыйфаларны алар арасында бүлгән боерыгы нигезендә бирелә.

3.21. Хезмәткәр отпускта булган чорда аның вазыйфаларын башкару структур бүлекчә җитәкчесе тарафыннан әлеге структур бүлекчәнең башка хезмәткәренә йөкләнә.

3.22. Отпускка гариза министр исеменә отпуск башланырга 10 көннән дә соңга калмыйча бирелә.

## Координацияләү һәм киңәшмә органнары

3.23. Министрлыкның хакимият координацияләү һәм киңәшмә органнарын, шулай ук оештыру комитетларын булдыру турындагы тәкъдиме министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары яки эшләр белән идарә итүче инициативасы буенча яки министр кушуы буенча мәсьәләләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышына карауга кертү өчен булдырылган тәртиптә әзерләнә.

3.24. Ведомтсвоара координацияләү һәм киңәшмә органнарына Министрлыктан вәкилләр кандидатуралары министр тарафыннан билгеләнә.

Министрлык хезмәткәрләрен ведомтсвоара координацияләү һәм киңәшмә органнары составына кертү турындагы тәкъдимнәр белән булган хат министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары һәм эшләр белән идарә итүче тарафыннан кертелә һәм билгеләнгән срок тәмамланырга 3 көннән дә соңга калмыйча, министр имзасы белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле органына җибәрелә.

3.25. Министрлык каршындагы Ведомствоара координацияләү һәм киңәшмә органнары ведомствоара әһәмияттәге документларны, шул исәптән норматив хокукый актлар проектларын әзерләү өчен булдырылалар.

Мондый органнарны булдыру һәм аларның составларын раслау Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынган органнары җитәкчеләре белән берлектә министр тарафыннан гамәлгә ашырыла. Министрның һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынган органнары җитәкчеләренең карары тиешле уртак боерык белән рәсмиләштерелә.

3.26. Министрлык тарафыннан булдырылган ведомтсвоара координацияләү һәм киңәшмә органнарын министр яки аның боерыгы нигезендә министрның бренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче җитәкли.

3.27. Ведомтсвоара координацияләү һәм киңәшмә органының эш планы аның җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

3.28. Ведомтсвоара координацияләү һәм киңәшмә органы эшчәнлеген оештыру һәм техник тәэмин итү оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге, хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге һәм тиешле структур бүлекчә тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.29. Иҗтимагый оешмаларның Министрлык вәкилләренең алар тарафыннан булдырылган органнар (иҗтимагый комиссияләр, советлар, эшче төркемнәр һәм башкалар) эшчәнлегендә катнашулары турындагы мөрәҗәгатьләре тиешле структур бүлекчәләр җитәкчеләре тарафыннан карала һәм министрга җиткерелә.

Министр тарафыннан кабул ителгән карар мондый мөрәҗәгать юллаган затка язма рәвештә юллана.

## Министрлык коллегиясе

3.30. Министрлык коллегиясе составы һәм саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана. Коллегия составына коллегия рәисе

булып торучы министр, министрның берернче урынбасары һәм министр урынбасарлары керә.

3.31. Министрлык коллегиясе эше аның утырышларында гамәлгә ашырыла. Коллегия утырышларында катнашучылар, коллегия әгъзаларыннан тыш, министр, коллегия утырышына документлар әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә башлыгы белән килештерү нигезендә билгеләнәләр.Министрлык коллегиясе турындагы нигезләмә министр боерыгы белән раслана.

3.32. Министрлык коллегиясенең эш планы министрлыкның структур бүлекчәләре тәкъдимнәре нигезендә формалаштырыла, министр тарафыннан раслана һәм коллегия әгъзаларына һәм башка кызыксынган затларга юллана.

## IV. Министрлыкта документлар әйләнеше эшен оештыруның төп кагыйдәләре

4.1. Министрлыкта документлар белән эшне оештыру кагыйдәләре Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Министрлыкта эшләр башкару буенча инструкция (алга таба – Эшләр башкару буенча инструкция) һәм әлеге Регламент белән билгеләнә.

4.2. Министрлыкта эш башкаруларны оештыру һәм алып бару өчен җаваплылык оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге башлыгына йөкләнә. Структур бүлекчәләрдә эш башкаруларны оештыру һәм алып бару өчен җаваплылык бүлекчәләр җитәкчеләренә йөкләнә.

4.3. Структур бүлекчәләр документлар белән тәэмин ителеш буенча турыдан-туры эшләр башкару өчен җаваплы затлар һәм функцияләре эшләрне башкару буенча инструкцияләр белән билгеләнә торган, аларны алыштыручы затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.4. Министрлыкта архив белән эш Архив эше турындагы закон нигезендә һәм Эшләр башкару буенча инструкция нигезендә алып барыла.

### Министр тарафыннан уздырыла торган киңәшмәләрдә кабул ителгән карарларны рәсмиләштерү

4.5. Министр тарафыннан атна саен оператив киңәшмәләр уздырыла, аларда министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче, структур бүлекчәләр башлыклары яки аларның вазыйфаларын вакытлыча башкаручы затлар, министр ярдәмчесе һәм министр тарафыннан билгеләнә торган башка затлар катнаша.

Киңәшмәнең эшләр белән идарә итүчесе оператив киңәшмәдә катнашучыларың барысына да тәкъдим итә:

киңәшмә беркетмәсен;

узган оператив киңәшмәләрдә бирелгән йөкләмәләрнең үтәлеше турында белешмәне;

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе (алар булган очракта) контролендәге йөкләмәләрнең үтлеше турындагы белешмәләрне.

4.6. Министр уздырган киңәшмәләрдә кабул ителгән карарлар беркетмә яки министр йөкләмәләре исемлеге белән рәсмиләштерелә. Киңәшмә беркетмәсе проекты рәсмиләштерелә, эшләр белән идарә итүче белән килештерелә һәм киңәшмә узганнан соңгы бер тәүлек дәвамында (әгәр дә министр тарафыннан документны әзерләүнең башка срогы билгеләнмәгән булса) министрга кертелә.

4.7. Министрлыкта шулай ук министр күрсәтмәсе нигезендә яки министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре инициативасы белән җыела торган башка киңәшмәләр дә уздырылырга мөмкин.

Мондый киңәшмәләрдә кабул ителә торган карарлар киңәшмә уздырылган көннән бер тәүлек дәвамында Министрлыкның киңәшмә уздыру өчен җаваплы булган структур бүлекчәсе башлыгы тарафыннан әзерләнә торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

4.8. Киңәшмә беркетмәләре электрон документлар әйләнеше системасы аша Министрлык җитәкчелегенә һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләренә юлланалар. Ведомствоара киңәшмә узган очракта беркетмә күчермәләре республиканың тиешле башкарма органнарына һәм оешмаларга, шулай ук Министрлыкның кызыксынган структур бүлекчәләренә юллана.

4.9. Министр тарафыннан уздырыла торган киңәшмәләр беркетмәләре күчермәләре башкаручыларга (шул исәптән башкарма хакимиятнең кызыксынган республика органнарына), кагыйдә буларак, бер тәүлек дәвамында, ә оператив һәм тиз сроклы йөкләмәләр булганнары – шул исәптән электрон элемтә чараларын да кулланып, кичекмәстән юллана.

Мондый киңәшмә беркетмәсендә булган йөкләмәләр үтәлешенә контрольү эшләр белән идарә итүче яки киңәшмәне уздыру өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.10. Оператив киңәшмә беркетмәсендә язылган йөкләмәне үтәү турындагы мәгълүматны структур бүлекчә җитәкчесе электрон рәвешә, башка срок билгеләнмәгән очракта, агымдагы атнаның җомгасыннан да соңга калмыйча, эшләр белән идарә итүчегә юллый.

## Министрлыкта боерыклар үтәлеше тәртибе

4.11. Министр боерыклары, күрсәтмәләре, шулай ук министр, министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче имзасы салынган башка документлар Министрлыкның оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге тарафыннан теркәләләр һәм башкаручыларга таратылалар.

4.12. Йөкләмәләрне структур бүлекчәләр башлыкларына җиткерү аларны Министрлыкта теркәү мизгеленнән соң бер тәүлек дәвамында, тиз сроклыларын – кичекмәстән гамәлгә ашырыла.

4.13. Йөкләмәләрне ял яки бәйрәм көннәре дәвамында үтәү мәҗбүрияте туган очракта оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге башлыгы мондый

йөкләмә килүе турында кичекмәстән Министрлык җитәкчелегенә хәбәр итә яки йөкләмәне үтәү буенча эшләрне мөстәкыйль рәвештә оештыра.

4.14. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты регламенты нигезендә "тиз срокклы" дип күрсәтелгән йөкләмә аны имзалау срогыннан алып 3 көн эчендә үтәлергә тиеш. "Оператив" дип күрсәтелгән йөкләмә имзалау датасыннан алып 10 көнлек срокны күздә тота.

Әгәр дә йөкләмәдә үтәү срогы күрсәтелмәгән икән,  ул имзаланган көннән алып бер ай эчендә (киләсе айның шушы көненә кадәр, әгәр дә киләсе айда андый сан юк икән, айның соңгы көненә кадәр) үтәлергә тиеш.

Әгәр дә срокның соңгы көне эш көне булмаган көнгә туры килә икән, ул эш көне булмаган көн алдыннан килә торган көн дәвамында үтәлеп бетәргә тиеш.

Йөкләмәне объектив сәбәпләр аркасында билгеләнгән вакыт эчендә үтәү мөмкин булмаган аерым очракларда (тиз сроклы һәм оператив йөкләмәләрдән тыш) структур бүлекчәләр башлыклары вазыйфаларның алар арасында бүленеше нигезендә министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче белән килештерү нигезендә, срокны озайту турында сәбәпләр һәм йөкләмәне үтәүнең планлаштырыла торган датасы күрсәтелгән,  алга таба Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелергә тиешле тәкъдимне министрга кертәләр. Мондый тәкъдимнәр министрга аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертү срогы чыгарга 3 көннән дә соңга калмыйча кертеләләр.

4.15. Йөкләмә Министрлык компетенцияләре чикләреннән чыккан очракта структур бүлекчәләр башлыклары аны үтәүне үз компетенцияләре чикләрендә тәэмин итәләр һәм вазыйфаларның алар арасында бүленеше нигезендә министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче белән килештерү нигезендә Татарстан Рспубликасы Министрлар Кабинетына кертү өчен йөкләмәне үтәргә ярдәм итүчеләрне җәлеп итү турындагы тәкъдимне министрга кертәләр.

Мондый тәкъдимнәр министрга йөкләмә имзаланганнан соңгы 7 көннән дә соңга калмыйча, ә тиз сроклы һәм оператив йөкләмәләр буенча – кичекмәстән кертеләләр.

4.16. Әгәр дә йөкләмәдә Министрык "созыв" сүзе белән билгеләнгән яки анда беренче итеп күрсәтелгән икән, бу очракта Министрлык йөкләмәне төп үтәүче булып тора, йөкләмәне үтәү буенча эшләрне оештыра һәм йөкләмә үтәлеше өчен җаваплы була.

4.17. Йөкләмәләрне билгеләнгән срокта үтәү өчен Министрлыкның структур бүлекчәсе җитәкчесе башкарма хакимият органнарының вәкаләтле вәкилләре – йөкләмәне үтәргә булышучылар, шулай ук башкарма хакимиятнең башка кызыксынган органнары һәм оешмалар вәкилләре (килештерү нигезендә) составындагы эшче төркем булдыру инициативасы белән чыга.

4.18. Әгәр дә Министрлык Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелгән йөкләмәсен үтәү буенча төп башкаручы булып тора икән, йөкләмәнең үтәлеше турындагы доклад проекты аннан соң Татарстан Республикасы Премьер-министрына яки Татарстан

Республикасы Премьер-министры урынбасарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесенә юллау өчен Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнгән срок чыгарга 6 көннән дә соңга калмыйча (әгәр дә Татарстан Республикасы Премьер-министры яки Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары тарафыннан башка срок билгеләнмәгән булса), Татарстан Республикасы Президентына доклад проекты теркәлеп, министрга кертелә.

4.19. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан йөкләмә турыдан-туры Министрга бирелгән очракта Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Премьер-министрына йөкләмә үтәлеше (яки үтәлеше барышы) турындагы тиешле докладлар проектлары тиешле срок тәмамланырга 3 көннән дә соңга калмыйча имзалау өчен министрга кертелә.

4.20. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан йөкләмә Татарстан Республикасы Премьер-министрына яки Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларына һәм бер үк вакытта министрга бирелгән, ә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан министрга йөкләмә бирелмәгән очракта Татарстан Республикасы Премьер-министрына (Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларына) йөкләмә үтәлеше турындагы доклад проекты, Татарстан Республикасы Президентына доклад проекты һәм кирәкле башка материаллар өстәлеп, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнгән срок чыгарга 6 көннән дә соңга калмыйча министрга кертелә.

4.21. Әгәр дә Министрлык йөкләмәне үтәргә булышучы булып торса, тиешле структур бүлекчәләр әлеге йөкләмәне үтәү өчен бирелгән срокның беренче яртысы дәвамында төп башкаручыга вазыйфаларның алар арасында бүленеше нигезендә министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче тарафыннан килештерелгән һәм министр тарафыннан имзаланган тәкъдимнәрне юллыйлар.

4.22. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышлары беркетмәләрендә, Татарстан Республикасы Премьер-министры тарафыннан уздырыла торган киңәшмәләр беркетмәләрендә, аның тарафыннан булдырылган координацияләү һәм киңәшмә органнары утырышлары беркетмәләрендә һәм резолюцияләрдә булган һәм аларны үтәү буенча Министрлык төп башкаручы булып торган йөкләмәләрнең үтәлеше турында министр Татарстан Республикасы Премьер-министрына хисап бирә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары уздырган киңәшмәләр беркетмәләрендә, ул оештыра торган координацияләү һәм киңәшмә органнары утырышлары беркетмәләрендә һәм резолюцияләрдә булган һәм аларны үтәү буенча Министрлык төп башкаручы булып торган йөкләмәләрнең үтәлеше турында министр Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарына хисап бирә.

4.23. Әгәр дә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелү өчен йөкләмәләрне үтәү йөзеннән әзерләнгән материаллар проектлары буенча (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышына актлар проектлары һәм материаллардан тыш) башкарма хакимиятнең республика органнары арасында

фикерләр каршылыгы бар икән, министрның беренче урынбасары, министр урынбасары, эшләр белән идарә итүче яки структур бүлекчә башлыгы министрга фикерләр каршылыгы турында, шулай ук башкарма хакимиятнең республика органнары – йөкләмәләрне үтәргә ярдәм итүчеләр җитәкчеләре (җитәкчеләр урынбасарлары) яки мондый органнарның вәкаләтле хезмәткәрләре катнашында уздырылган килештерү процедуралары һәм киңәшмәләр нәтиҗәләре турында белдерәләр. Монда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына материаллар белән берлектә килештерү процедуралары уздырылу турындагы мәгълүмат та кертелә.

4.24. Йөкләмә үз вакытында үтәлмәгән очракта структур бүлекчә башлыгы - йөкләмәне төп башкаручы йөкләмәне үтәү өчен каралган срок чыкканнан соң 2 көн дәвамында министрга вазыйфаларның алар арасында бүленеше нигезендә министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче белән килештерелгән, йөкләмәнең үтәлеше барышы турында йөкләмәне үтәү вазыйфалары аларга йөкләнгән вазыйфаи затлар, йөкләмәнең тиешле вакытта үтәлмәвенең сәбәпләре һәм йөкләмәнең үз вакытында үтәлмәве өчен гаепле затларга карата куллану тәкъдим ителә торган яки кулланылган чаралар күрсәтелгән язма аңлатманы тапшыра.

Министр тарафыннан кабул ителгән карар нигезендә тиешле структур бүлекчә җитәкчесе аңа бер тәүлек дәвамында аннан соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллау өчен тиешле аңлатма проектын кертә.

4.25. Йөкләмәләрне үтәгән чакта Министрлыкның йөкләмәдә беренче итеп күрсәтелгән яки “созыв” сүзе белән билгеләнгән структур бүлекчәсе йөкләмәне төп үтәүче булып тора. Әлеге сруктур бүлекчә башлыгы йөкләмәне үтәү буена эшләрне оештыра һәм аның үтәлеше өчен җаваплы була.

4.26. Йөкләмә йөкләмәдә бигеләнгән структур бүлекчәләр – йөкләмәне үтәү эшендә ярдәмчеләр компетенцияләре чигеннән чыга икән, әлеге структур бүлекчәләр башлыклары аны үтәүне билгеләнгән компетенцияләр чикләрендә тәэмин итәләр. Мондый очракта төп башкаручы йөкләмәне биргән җитәкчегә йөкләмә теркәлгән көннән алып 2 календарь көн эчендә, ә тиз сроклы һәм оператив йөкләмәләр буенча - кичекмәстән йөкләмәне үтәү эшендә ярдәмчеләр составы үзгәрү яки яңа ярдәмчеләр җәлеп итү турында өстәмә тәкъдимнәр кертә. Мондый очракларда төп башкаручы Министрлыкның әлеге мәсьәләне карау алар компетенциясенә керә торган структур бүлекчәләреннән мәгълүматны мөстәкыйль рәвештә соратып ала ала.

4.27. Структур бүлекчәләр – үтәү эшендә ярдәмчеләр йөкләмәне үтәү өчен билгеләнгән срокның беренче яртысы дәвамында төп башкаручыга әлеге структур бүлекчәләр башлыклары тарафыннан имзаланган тәкъдимнәрне кертәләр.

Үтәү эшендә ярдәм итүчеләр тәкъдимнәрне үз вакытында кертү һәм аларның сыйфатлы булулары өчен җавап бирәләр. Тәкъдимнәр үтәү эшендә ярдәм итүчеләр тарафыннан үз вакытында кертелмәгән очракта төп башкаручы йөкләмәне биргән җитәкчегә бу хакта белдерә.

4.28. Әгәр дә йөкләмәне үтәүнең билгеләнгән срогы 3 көннән кимрәк икән, төп башкаручы йөкләмәне үтәү буенча эшне кичектергесез рәвештә оештыра.

4.29. Министрның, министрның беренче урынбасарының, министр урынбасарларының, эшләр белән идарә итүченең йөкләмәләре тиешле срокта үтәлмәгән очракта, йөкләмәне төп башкаручы әлеге йөкләмәне үтәү өчен каралган срок чыга торган көндә министрга, министрның беренче урынбасарына, министр урынбасарларына, эшләр белән идарә итүчегә йөкләмәнең үтәлеше барышы турында йөкләмәне үтәү вазыйфалары аларга йөкләнгән вазыйфаи затлар, йөкләмәнең тиешле вакытта үтәлмәвенең сәбәпләре һәм йөкләмәнең үз вакытында үтәлмәве өчен гаепле затларга карата куллану тәкъдим ителә торган яки кулланылган чаралар күрсәтелгән язма аңлатманы тапшыра.

Министрга бирелә торган аңлатма вазыйфаларның алар арасында бүленеше нигезендә министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче тарафыннан килештерелә.

## Министрлыкта йөкләмәләр үтәлешенә контроль

4.30. Министрның, министр тарафыннан тиешле вәкаләтләр бирелгән министрның беренче урынбасарының, министр урынбасарларының, эшләр белән идарә итүченең, структур бүлекчәләр җитәкчеләренең йөкләмәләрен дә кертеп, йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдә тоту оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.31. Министрлык, Министрлык тарафыннан карала торган закон проектлары буенча йөкләмәләрне дә кертеп, йөкләмәләрне үтәргә ярдәм итүче буларак билгеләнгән очракта, йөкләмәләрне үтәүне контрольдә тоту тиешле структур бүлекчәләрнең Министрлык тарафыннан тиешле документларның (тәкъдимнәрнең, бәяләмәләрнең, актлар проектларының һәм башка материалларның) тиешле тәртиптә йөкләмәне төп башкаручыга җибәрелүе яки актлар проектларының килештерелүе турында документлаштырылган мәгълүматлары нигезендә туктатыла.

4.32. Гражданнардан һәм оешмалардан Министрлыкка кергән мөрәҗәгатьләрне карауны контрольдә тоту аларга җаваплар әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәләр башлыклары тарафыннан, шулай ук оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла. Мондый контроль тиешле структур бүлекчәләрнең мөрәҗәгать итүчегә Министрлык тарафыннан тиешле тәртиптә җавап җибәрелүе турында документлаштырылган мәгълүматы нигезендә туктатыла.

## V. Аның тарафыннан эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә норматив җайга салуны гамәлгә ашырганда Министрлыкның норматив хокукый актларны әзерләү һәм кабул итү тәртибе

5.1. Норматив хокукый актлар законнар һәм Министрлыкта эшләр башкару инструкциясе нигезендә Министрлык тарафыннан боерыклар рәвешендә чыгарыла.

5.2. Норматив хокукый акт проектын әзерләүне һәм килештерүне тиешле структур бүлекчә гамәлгә ашыра. Министрлыкның норматив хокукый актлары проектлары норматив хокукый актларны теркәү һәм Министрлык эшчәнлеген

хокукый тәэмин итү бүлеге белән, ә финанс йөкләмәләрен күздә тоткан актлар проектлары – финанс бүлеге белән мәҗбүри рәвештә килештерелергә тиеш.

Министрлыкның норматив хокукый актлары министр яки аның вазыйфаларын башкаручы зат тарафыннан имзалана.

Министрлыкның структур бүлекчәләре норматив хокукый актлар чыгара алмыйлар.

5.3. Аларны әзерләү буенча җаваплылык Министрлыкка йөкләнгән ведомствоара характердагы актлар проектларын әзерләү максатыннан министр башкарма хакимиятнең федераль органнарының кызыксынган территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары белән килештереп, ведомствоара эш төркеме җыярга хокуклы.

Әлеге норматив хокукый актлар проектларын килештерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелә торган норматив хокукый актлар проектларын килештерүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты регламентында билгеләнгән тәртиптәге кебек булган тәртибендә гамәлгә ашырыла.

5.4. Вазыйфаларның алар арасында бүленеше нигезендә министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре норматив хокукый акт проектын килештерүне тәэмин итәләр, шул исәптән килештерү буенча киңәшмәләр уздырып та (фикерләр каршылыгы килеп чыкканда).

Акт проекты буенча җайга салынмаган фикерләр каршылыгы очрагында вазыйфаларның алар арасында бүленеше нигезендә министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче министрга әлеге фикерләр каршылыгы турында хәбәр итәләр һәм аның күрсәтмәләре нигезендә гамәл кылалар.

## VI. Министрлыкта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелә торган актлар проектларын әзерләү һәм карау тәртибе

### Актлар проектларын кертү тәртибе

6.1. Структур бүлекчәләр тарафыннан әзерләнгән актлар проектлары тиешле исәп-хисапларны, социаль-икътисадый фаразлар нигезләмәләрен, тәкъдим ителә торган карарларның финанс һәм башка нәтиҗәләрен үз эченә алган аңлатмалар белән берлектә вазыйфаларның алар арасында бүленеше нигезендә министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче тарафыннан килештереләләр, имзаланалар һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты регламентында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертеләләр.

6.2. Актлар проектлары алар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелгәнчегә кадәр башкарма хакимиятнең кызыксынган республика органнары белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты регламентында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри рәвештә килештерелергә тиешләр.

Килештерү өчен Министрлыкка кертелгән актлар проектларын карау тәртибе

6.3. Килештерү өчен Министрлыкка кертелгән актлар проектлары аңлатма белән берлектә һәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше юлы белән карау өчен тиешле структур бүлекчәләргә, министрның беренче урынбасарына, министр урынбасарларына, эшләр белән идарә итүчегә һәм министр резолюциясе нигезендә башка вазыйфаи затларга юлланалар.

6.4. Әлеге документлар структур бүлекчәләр башлыклары, вазыйфаларның алар арасында бүленеше нигезендә министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче, министр тарафыннан Татарстан Республикасы министрлар Кабинеты регламентында билгеләнгән срокларда каралалар һәм килештереләләр.

Хокукый характердагы фикер каршылыклары булганда актлар проектлары килештерелми, юридик-техник характердагы фикер каршылыклары булганда кисәтүләр белән килештерелә. Фикер каршылыклары башкаручы тарафыннан электрон документ карточкасында теркәлә һәм вазыйфаларның алар арасында бүленеше нигезендә структур бүлекчә башлыгы, министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче белән килештерү аша имзалау өчен министрга кертелә.

## VII. Министрлыкның закон чыгару эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшендә катнашу тәртибе

### Министрлыкның закон чыгару эшчәнлеген планлаштыру һәм аны оештыру тәртибе

7.1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норма чыгару эшчәнлеген координацияләү һәм хокукый тәмин итү (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүләрен контрольдә тоту) функцияләрен эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә гамәлгә ашыру максатыннан Министрлык, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару эшчәнлеге планнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эш планы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыклары һәм тиешле йөкләмәләре, шулай ук шәхси инициативасы нигезендә дә, Татарстан Республикасы законнары проектларын эшли.

7.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару эшчәнлеге планы проектына кертү өчен Министрлык тарафыннан Татарстан Республикасы закон проектларын эшләү турындагы тәкъдимнәр структур бүлекчәләр тарафыннан хокукый экспертиза һәм норма чыгару эше бүлегенә кертелә.

Күрсәтелгән тәкъдимнәр үз эченә алырга тиешләр:

законны кабул итү кирәклеген нигезләүне;

закон проектының үз эченә аның гомуми характеристикасын һәм төп нигезләмәләрен алган концепциясен;

закон проектын әзрләү этапларын һәм закон проектын эшләүчеләрнең исемлеген;

закон проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертү срогын;

закон проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертүнең якынча срогын.

7.3. Структур бүлекчә тарафыннан вәкаләтләрнең билгеләнгән даирәсен исәпкә алып эшләнгән закон проекты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты регламентында билгеләнгән кирәкле материаллар белән берлектә хокукый экспертиза һәм норма чыгару эше бүлегенә юллана.

Закон проектын ахыргача эшләп бетерү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертү хокукый экспертиза һәм норма чыгару эше бүлеге тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

## Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшендә катнашу

7.4. Министр, министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче, структур бүлекчәләр җитәкчеләре (министр боерыгы нигезендә) Министрлык компетенциясенә карый торган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы регламенты нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшендә катнаша алалар.

7.5. Министрлыкта аның вәкилләренең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшчәнлегендә катнашуларын тәэмин итү буенча эшне координацияләү министр тарафыннан билгеләнгән вазыйфаи затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7.6. Министр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чакыруы буенча утырышта катнаша һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары сорауларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы регламентында каралган тәртиптә җавап бирә.

7.7. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында катнашу мөмкин булмаган очракта министр утырыш уздырылырга 2 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисен үзенең утырышта катнаша алмавы сәбәбен әйтеп һәм үзенең утырышта катнашу һәм куелган мәсьәләләргә җавап бирү бурычы йөкләнгән вәкаләтле вәкилен күрсәтеп, кисәтә.

## Министрлыкта депутат запросларын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе

7.8. Татарстан Республикасы Премьер-министрына, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларына депутат запросына җавап проектын әзерләү аларның йөкләмәләре буенча Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7.9. Җавап проектын әзерләү өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең берничә органы катнашуы таләп ителгән очракта аны әзерләү һәм килештерү Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасалары йөкләмәләрен үтәү тәртибенә мөнәсәбәттә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышлары беркетмәләрендә булган йөкләмәләрне үтәү тәртибенә мөнәсәбәттә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты регламентында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

7.10. Әгәр дә Министрлык депутат запросына җавапны төп әзерләүче булып тора икән, запроска җавап проекты тиешле нигезләү документлары белән берлектә һәм йөкләмәдә күрсәтелгән срокларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелә.

7.11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Премьер-министрына яки аның урынбасарларына булган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан Министрлыкка килгән депутат запрослары, шулай ук министрга депутат запросы карау һәм җаваплар әзерләү өчен тиешле структур бүлекчәләр җитәкчеләренә юлланалар.

7.12. Министрлыкның структур бүлекчәсе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан килгән депутат запросын мондый запроска җавап Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Премьер-министры яки аның урынбасарлары тарафыннан запрос алынганнан соңгы 30 көннән дә соңга калмыйча яки Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнгән башка срок нигезендә бирелергә тиешлеген исәпкә алып карый.

Монда запросны алу көне булып запросның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына керү көне санала.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына депутат запросына җавап проекты белән булган, структур бүлекчә тарафыннан әзерләнгән һәм вазыйфаларның алар арасында бүленеше нигезендә министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче белән килештерелгән хат проекты запросны юллаган затка җавап бирелергә тиешле срок чыкканчыга кадәрге 10 көннән дә соңга калмыйча имзалау өчен министрга юллана.

7.13. Министрга булган депутат запросына структур бүлекчәләр тарафыннан әзерләнгән һәм вазыйфаларның алар арасында бүленеше нигезендә министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче белән килештерелгән җавап проекты запросны юллаган затка җавап җибәрелергә тиешле срок чыгарга 3 көннән дә соңга калмыйча имзалау өчен министрга кертелә.

7.14. Депутат мөрәҗәгатенә җавап, депутат мөрәҗәгате теркәлгән көннән 7 көн эчендә каралырга тиешлекне исәпкә алып, структур бүлекчә тарафыннан әлеге Регламентның 7.8-7.13 пунктларында билгеләнгән тәртиптә карала.

7.15. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләренең аларның эшләрне карау вәкаләтләре буенча Татарстан Республикасы Премьер-министрына, Татарстан Республикасы Премьер-министры

урынбасарларына булган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан Министрлыкка килгән мөрәҗәгатьләре тиешле структур бүлекчәләр башлыкларына юлланалар һәм алар тарафыннан мондый мөрәҗәгатьләрдә билгеләнгән срокларда каралалар. Мөрәҗәгатьләргә җаваплар күчермәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына юлланалар.

## VIII. Министрлык мәнфәгатьләрен суд органнарында тәкъдим итү

8.1. Министр судта Министрлык вәкиле буларак чыгыш ясый ала һәм аның исеменнән барлык процессуаль гамәлләрне кылырга хокуклы, шул исәптән иск гаризасын һәм иск гаризасына бәяләмәне, искны тәэмин итү турындагы гаризаны имзаларга һәм иск таләпләреннән һәм искны танудан тулысынча яки өлешчә баш тартырга, иск нигезләмәләрен һәм предметын үзгәртергә, башка процессуаль документларны имзаларга, мировой килешү төзергә, шулай ук суд актларына шикаять белдерергә, яңа билгеле булган мәгълүматлар нигезендә суд актларын кабат карау турында гариза имзаларга, башкарма документларны алуга, даулап алынган акчаларны һәм башка мөлкәтне алуга да.

Министрлыкның башка вәкилләре вәкаләтләре министр тарафыннан бирелә торган ышаныч кәгазендә билгеләнә.

8.2 Ышаныч кәгазе нигезендә Министрлык вәкиле буларак чыгыш ясаучы зат министрга эшнең судта каралу нәтиҗәләре турында утырыш узган көндә яки утырыш узган көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча хисап бирә.

8.3. Министрлыкка куелган таләпләр суд тарафыннан канәгатьләндерелгән очракта ышаныч кәгазе нигезендә Министрлык вәкиле буларак чыгыш ясаучы зат кабул ителгән карар турында министрга кичекмәстән хәбәр итә, суд карарына шикаять белдерү турында, кирәк булган очракларда – аны гамәлгә ашыру чаралары турында тәкъдим кертә.

## IX. Гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе, гражданнарны Министрлыкта кабул итү

9.1. Министрлыкта шәхси һәм коллектив тәкъдимнәр, гражданнар һәм оешмаларның Министрлык эшчәнлеге өлкәсенә карый торган, аларның дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру тәртипләренә, дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә кагылышлы һәм электрон хәбәрләр формасында (электрон почта, Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе аша яки башка алым белән кергән) яки гражданнарны кабул итү барышында вазыйфаи затка телдән шәхси мөрәҗәгать формасында кергән гаризалары һәм мөрәҗәгатьләре (алга таба – гражданнар мөрәҗәгатьләре) карала.

9.2. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе, шулай ук гражданнарга аларның мөрәҗәгатьләре буенча, шул исәптән белешмә характерындагы мәгълүматларны бирү тәртибе Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

9.3. Министрлыкка гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне теркәү, аларны исәпкә алу һәм аларны карау срокларын контрольдә тоту Министрлыкның оештыру

эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге тарафыннан Бүлек турындагы нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

9.4. Министрлыкка кергән язма мөрәҗәгатьләр, шулай ук Министрлык яки министр актларына шикаятьләр теркәлү узалар һәм министр тарафыннан вазыйфаларның алар арасында бүленеше нигезендә мөрәҗәгатьне карап җавап әзерләү өчен министрның беренче урынбасарына, министр урынбасарларына, эшләр белән идарә итүчегә юлланалар.

9.5. Гражданнарның Министрлыкның конкрет вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләре карау һәм (яки) мөрәҗәгать итүчегә җавап бирү өчен әлеге вазыйфаи затларга юллана алмыйлар.

9.6. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре Министрлык тарафыннан алар теркәлгән көннән алып 30 көн дәвамында каралалар. Аерым очракларда язма мөрәҗәгатьне карау срогы министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче тарафыннан вазыйфаларның алар арасында бүленеше нигезендә мөрәҗәгать язучыны бу хакта кисәтеп һәм мөрәҗәгатьне карау срогы озайтылу сәбәпләрен аңлатып, 30 көннән дә артыграк булмаган вакытка озайтыла ала.

9.7. Язма мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгатьне юллаган гражданинның фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән очракта мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Әлеге мөрәҗәгатьтә хокукка каршы эшчәнлек әзерләнелүе, кылынырга җыенуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук хокукка каршы эшчәнлекне әзерләгән, кылырга җыенган яки кылган зат турында мәгълүматлар булган очракта мөрәҗәгать бу мөрәҗәгатьне карау компетенциясендә булган дәүләт органына юллана.

9.8. Суд карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгать мөрәҗәгать теркәлгәннән соңгы 7 көн дәвамында, әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибе аңлатылып, мөрәҗәгатьне юллаган гражданинга кире кайтарыла.

9.9. Цензурасыз яки кимсетүле сүзләр, вазыйфаи затның тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә, шулай ук аның гаилә әгъзаларына янау булган язма мөрәҗәгать алынганда Министрлык мөрәҗәгатьне җавапсыз калдырырга һәм мөрәҗәгатьне юллаган гражданинны болай эшләү рөхсәт ителмәве турында кисәтергә хокуклы.

9.10. Язма мөрәҗәгать текстын укып булмау очрагында мөрәҗәгатькә җавап җибәрелми һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки аларның компетенцияләре буенча вазыйфаи затка да җибәрелми, бу хакта, әгәр дә мөрәҗәгать җибәрүченең фамилиясен һәм почта адресын укып булган очракта, мөрәҗәгатьне юллаган гражданинга мөрәҗәгать теркәлгәннән соңгы 7 көн дәвамында хәбәр ителә.

9.11. Гражданинның язма мөрәҗәгатендә әлеге мәсьәлә буенча элегрәк килгән мөрәҗәгатьләр буенча Министрлык тарафыннан күп тапкырлар язма җаваплар юлланган мәсьәлә күтәрелгән һәм яңа мөрәҗәгатьтә бернинди дә яңа дәлилләр китерелмәгән очракта, министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче алар арасында бүленгән вазыйфалар нигезендә яңа мөрәҗәгатьнең нигезсез булуы һәм гражданин белән әлеге мәсьәлә

буенча хат язышуны туктату турында карар кабул итәләр. Мөрәҗәгать юллаучы гражданинга әлеге карар турында хәбәр ителә.

9.12. Министрлыкта, әгәр дә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары белән башкасы билгеләнмәгән булса, килешүләргә, шулай ук оешмаларның гамәлгә кую һәм башка документларына экспертиза уздыру турындагы мөрәҗәгатьләр каралмый.

9.13. Әлеге очракларда структур бүлекчәләр җитәкчеләре мөрәҗәгать итүчеләрне бу хакта кисәтәләр.

9.14. Әгәр дә гражданнар тарафыннан кергән мөрәҗәгатьтәге мәсьәләләр Министрлык компетенциясенә керми икән, мөрәҗәгать теркәлгәннән соңгы 7 көн дәвамында тиешле органга яки тиешле вазыйфаи затка юллана. Мөрәҗәгатьнең башка урынга юлланую турында мөрәҗәгать итүчене мәгълүматлаштыру тиешле структур бүлекчә җитәкчесе тарафынан башкарыла.

9.15. Гражданнар мөрәҗәгатьләре аларда куелган барлык сораулар каралган һәм алар буенча тиешле чаралар күрелеп, гражданнарга язма җаваплар җибәрелгәннән соң хәл ителгән булып санала. Кабат мөрәҗәгать ителгән очракта гражданнарның хәл ителгән мөрәҗәгатьләрен өстәмә карау әлеге мөрәҗәгатьтә карала торган мәсьәләгә кагылышлы өлкәдә норматив хокукый җайга салу үзгәргәндә яки яңа мәгълүматлар билгеле булган чакта гамәлгә ашырыла.

9.16. Оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге һәр квартал нәтиҗәләре буенча гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализларны гомумиләштерә һәм әлеге мәгълүмат проектын имзалау һәм алга таба Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына юллау өчен министрга бирә.

9.17. Дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, Министрлык турындагы нигезләмә һәм әлеге Регламент бозылу турында Министр исеменә килгән шикаятьләр вазыйфаларның алар арасында бүленеше нигезендә министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче тарафыннан, тиешле структур бүлекчәләр тарафыннан әзерләнгән бәяләмәләр белән берлектә, шикаять теркәлгәннән соңгы 10 көн эчендә министрга җиткерeләләр.

9.18. Министрлыкка элегрәк килгән мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча гражданнардан министр исеменә килгән шикаятьләр җавап бирү өчен Министрның беренче урынбасарына юлланалар, аңа юлланган җавапка шикаять килү очрагыннан тыш. Андый шикаять министр тарафыннан шәхсән карала.

9.19. Электрон почта аша килгән мөрәҗәгатьләргә җавап язма формада да, электрон хәбәр формасында да юллана ала.

9.20. Гражданнарны министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче тарафыннан кабул итү оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге тарафыннан министр тарафыннан расланган график нигезендә эш көннәрендә оештырыла. Министр гражданнарны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән, гражданнарны шәхси мәсьәләләр буенча кабул итү көнендә гамәлгә ашыра (һәр сишәмбе 14.00 сәгатьтән).

9.21. Гражданнарны кабул иткән чакта алар тарафыннан куелган мәсьәләне хәл итеп булмаган очракта, язма мөрәҗәгать кабул ителә, ул теркәлгәннән соң тиешле структур бүлекчәгә карауга җибәрелә.

Гражданнарны кабул иткән чакта алар тарафыннан куелган мәсьәләне хәл итү Министрлык компетенциясенә кермәгән очракта, гражданга дәүләт хакимиятенең тиешле органына мөрәҗәгать итү тәртибе аңлатыла.

9.22. Министр, министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары министр тарафыннан расланган график нигезендә гражданнарны күчмә кабул итәләр.

## X. Министрлык эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү

10.1. Министрлык үз эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны “Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алуны тәэмин итү хакында” 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасының дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алуны тәэмин итү хакында” 2015 елның 16 гынварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы һәм Мәгълүматтан файдаланучыга анның мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеге турында мәгълүмат бирүнең министрның 2012 елның 29 декабрендәге №01-02/106 номерлы боерыгы белән расланган тәртибе нигезендә бирә.

10.2. Министрлык Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Регламент нигезендә гражданнарның һәм оешмаларның Министрлык эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны алуларын, шул исәптән әлеге мәгълүматны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә “Татарстан Республикасының рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми сайтына урнаштыру һәм актуаль хәлдә тоту юлы белән, тәэмин итә.

10.3. Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыру өчен мәгълүмат структур бүлекчәләр башлыклары тарафыннан Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми сайтын “Татарстан Республикасының рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составында тотуның 2011 елның 26 октябрендәге 01-02/62 номерлы регламенты нигезендә биреләләр.

10.4. Министрлыкның үз карамагындагы эшчәнлеге турында мәгълүматны үз вакытында бирү, аның тулылыгы һәм дөреслеге өчен министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче, министр ярдәмчесе җаваплылык тоялар.

10.5. Гражданнарны һәм оешмаларны Министрлык эшчәнлеге турында Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмат белән тәэмин итү өчен җаваплылык хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге эшчәнлегенә җитәкчелек итә торган министр урынбасарына йөкләнгән.

## XI. Килешүләр (контрактлар, ризалыклар) әзерләү, аларны рәсмиләштерү

11.1. Килешүләр (контрактлар, ризалыклар) проектлары министрның, министрның беренче урынбасарының, министр урынбасарларының, эшләр белән идарә итүченең боерыкларын үтәү йөзеннән структур бүлекчәләр тарафыннан Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары таләпләре нигезендә һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында контракт нигезендә хезмәт итү турындагы нигезләмә (2013 елның 31 гыйнварында министрның 01-02/156 боерыгы нигезендә расланган) нигезендә әзерләнә.

11.2. Килешүләрнең (контрактлар, ризалыклар) структур бүлекчә тарафыннан әзерләнгән, шулай ук контрагент тарафыннан кертелгән проектлары финанс бүлеге башлыгы һәм норматив хокукый актларны теркәү һәм Министрлык эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы белән килештерелергә тиеш.

## XII. Министрлык тарафыннан дәүләт хезмәтләрен тәкъдим итү

12.1. Министрлык тарафыннан гражданнарга һәм оешмаларга дәүләт хезмәтләрен тәкъдим итү “Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ номерлы Фдераль закон һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең министр боерыгы нигезендә расланган административ регламентлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

12.2. Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентлары проектларын эшләүне тиешле дәүләт хезмәтләрен тәкъдим итүче структур бүлекчәләр гамәлгә ашыра.

## XIII. Министрлыкның судьялык оешмалары, Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы һәм адвокатлар белән хезмәттәшлеге

13.1. Министрлык Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеген тәэмин итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда судьялык оешмалары белән хезмәттәшлек итә.

13.2. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтле органы функциясен гамәлгә ашырганда һәм кыен тормыш шартларында калган гражданнарга экстрен очракларда түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында карар кабул иткәндә Министрлык Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы һәм түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең дәүләт системасында катнашучы адвокатлар белән хезмәттәшлек итә.